ЭТ КАДЕРЕ
Бер этне приютта яшәтү көненә 150 сумга төшә
> 2

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:
«Республика – тотрыклы төбәкләр төркемендә»
> 3

ЧЫРШЫЛЫ ЯЛ
Яңа ел бәйрәмнәрендә кая барырга?
> 8

КЫШКЫ ТӘНӘФЕС
Футболчылар ике атналык ялга китте
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 184 (29151) | Чәршәмбе | 13 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

Табигать кыланмышлары

САЛКЫН СЫНАУ

Кыш үзенекен итә. Бу көннәрдә республиканың кайбер районнарында термометр баганасы 50 градуска кадәр (!) төште. Халык мамык шәлгә төренгән арада, җылылык белән тәэмин итүчеләргә дә эш артты. Салкыннар көчәйгән көннәрдә газ һәм электр энергиясен куллану буенча рекорд теркәлгән. Синоптиклар исә тынычландырырга ашыга: атна азагына җылытачак. Бу кыштан нәрсә көтәргә?

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Узган атна ахырында өй каршындагы градусник 47 градус салкын күрсәтте, – ди Әгерҗе районының Тирсә авылы китапханәчесе Раушания Галләмова. – Алдагы елларда 40 градус салкын булганы бар иде үзе. Тик быелгы кыш уздырды. Бу кадәр салкынны хәтерләмим. Безнең якта 50 градуска кадәр суытты, дип әйтүчеләр дә бар. Өйдә җылы анысы, газ эшли. Сулар катмады, авыл җирендә ул да бик мөһим. Җитәкчелек бу эшне карап-тикшереп тора. Бу арада күршеләрнең, бигрәк тә ялгыз яшәүче өлкәннәрнең хәлен гел белешеп торабыз. Минем дә күршемдә бер әби бар. Көн дә кереп, хәл-әхвәлләрен сорашып чыгам. Аның каравы балалар укудан ял итте. Салкын булгач, атна ахырыннан бирле мәктәпкә бармыйлар. Балалар бу атна башында да өйдә әле. Чөнки сишәмбе иртән урамда 30 градус салкын иде. Алга таба мондый суыклар булмас инде, бәлки. Хәер, авыл кешесе кышкы салкынга өйрәнгән ул. Өйдә генә ятып булмый, ишегалдында мал-туар, кош-корт та бар бит әле. Кыш буе аяктан итек төшми. «Дежур» аяк киеме гел ишек төбендә тора. Зарланмыйбыз. Тавыклар да сарайдан чыкты инде. Димәк, салкынга бирешмиләр.

КФУның Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев сүзләренә караганда, бездә Арктикадан килгән һава торышы хакимлек итә, шуңа күрә дә көннәр гадәттәгедән салкынрак.

Бу – бер Татарстанга гына хас күренеш түгел, илнең күп кенә төбәкләрендә шул ук хәл, – ди белгеч. – Вазгыять бу көннәрдә үк үзгәрәчәк. Салкын һава акрынлап бирешә. Аның урынына көньяк-көнчыгыштан җылы җилләр исә башлады инде. Шунысын да искәртик: бу суыклар декабрь өчен гайре табигый күренеш түгел. Тарихка күз салсак, кышның беренче аенда моннан салкынрак көннәр дә билгеле.

Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, Татарстанда быелгы декабрь климатик нормаларга якын булачак.

– Ай башында сизелерлек салкын булды икән, димәк, ай ахырында көтмәгәндә җылытып җибәрергә дә мөмкин, – ди ул. – Кайбер фаразларга караганда, декабрьнең соңгы ун көнендә һава температурасының 0 градус тирәсендә тирбәлүе ихтимал. Тик борчылмагыз, Яңа елда кар эреп бетмәячәк. Гомумән, башкалада, мәсәлән, кар биеклеге 19 сантиметр тәшкил итә, ә алдагы елларда бу вакытта әлеге күрсәткеч 13 сантиметрдан да артмады. Шуңа күрә көннәр салкын дип уҗымнар өчен борчыласы юк. Татарстанда кар катламы җитәрлек.

Кыш суыкларсыз булмас, әлбәттә. Тик салкыннар көчәйгән көннәрдә халыкны электр энергиясе һәм газ белән тәэмин итүчеләргә эш арткан. 6–8 декабрьдә Татарстан халкы гына да 5016 мВт электр энергиясе яккан. Бу – рекорд сан, дигәннәр тармакта. Моңа кадәр республикада иң күп чимал тотылган көн узган елның гыйнвар суыкларына (4950 мВт чамасы. – **Ред.**) туры килгән булган. Татарстаннан тыш, бу көннәрдә утны Красноярск крае, Иркутск өлкәсе, Ингушетия, Саха (Якутия) республикаларында яшәүчеләр дә күбрәк тоткан.

Газны да күбрәк якканбыз. «8 декабрьдә «Газпром» бүлекчәләре ил кулланучыларына бер тәүлек эчендә 1717 миллион куб метр газ җибәргән. Декабрьдә бу кадәр зур күрсәткеч теркәлгәне юк иде әле», – диелгән оешма хәбәрендә. Эш артуны, әлеге дә баягы, илнең кайбер төбәкләрендә көннәр кинәт суытып җибәрүгә бәйләп аңлатканнар.

Ут яккан, торбаларны җылыткан өчен түләргә дә туры киләчәк. Бу хакта Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов декабрь башында әле каты суыклар башланганчы ук кисәтте.

– Гадәттә, гыйнвар, февраль айлары салкынрак булып саналса да, быел декабрьдә үк суыта, димәк, җылылык тагын да күбрәк тотылачак, – диде ул киләсе айда киләчәк счет-фактура кәгазьләренең кыйммәтрәк булачагына ишарәләп. – Кышкы чорда болай да күп түлибез. Коммуналь түләү кәгазьләренә җылылык өчен шактый акча өстәлә. Бу кышта 2022 елның 1 декабрендә расланган тарифлар буенча исәп-хисап ясалачак. Шуңа күрә үзгәреш юк. Артык акча түләмәс өчен өйдәге исәпләгечләрне карап-тикшереп торырга да киңәш итәбез.

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев исә декабрь суыклары июньдә сөендерергә мөмкин, дигән фикердә.

– Ике ел рәттән декабрь чагыштырмача җылы килде. Шуңа күрә быелгы суыклар катырак булды. Мондый салкынга ияләшмәгән дә идек. Ничек кенә булмасын, төп суыклар гыйнварның икенче яртысында көтелә әле. Быелгы кышка карап, җәй киләчәк, дип уйлыйм. Соңгы елларда июнь ае бик салкын, тик декабрьдәге һава торышын исәпкә алганда, киләсе елга җәйнең беренче ае кояшлы, җылы булырга охшаган, – ди ул.

Хәрбиләргә – яңа өстенлек

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары эшкә өстенлекле рәвештә урнашу хокукына ия булачак. Президент Владимир Путин «Россия Федерациясендә яшәүчеләрнең мәшгульлеге турында» законны яңа редакциядә имзалаган. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми сайтына урнаштырылган.

«РИА Новости» хәбәренә караганда, узган атнада закон проектын Федерация Советы хуплаган булган.

Документта шулай ук эшсезлек буенча пособиенең чик күләме билгеләнгән. Беренче 3 айда – 12,7шәр мең, шуннан соңгы 3 айда – 5әр мең сум түләнелә. Ә инде пособиенең иң кечкенә күләме – 1,5 мең сум. «Эшсез» статусын алу өчен, кешенең үзенә яраклы эш, бурычлары турында шәхси планны килештерергә кирәк булачак. Документны «Работа в России» сервисы ярдәмендә мәшгульлек хезмәтендә эшләүчеләр тәкъдим итәчәк.

Авыр йөк

Барлык уку йортларын саклау өчен, Росгвардиягә 700 меңгә якын яңа хезмәткәр һәм бер елга 600 миллиард сум чамасы акча кирәк. Росгвардия башлыгы киңәшчесе Игорь Пышкин билгеләп үткәнчә, ил бюджеты өчен гаять зур йөк бу. Аның әйтүенчә, күпмедер вакыт узганнан соң да боларны гамәлгә ашыру җиңел генә булмаячак әле. «Хәзерге вакытта мәктәпләрдә шәхси сак компаниясе хезмәткәре, тимер кыса һәм хәтәр турында кисәтүче төймә генә бар», – дигән ул.

Мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсе шушы араларда гына Брянск шәһәрендә булган фаҗигадән соң янә калкып чыкты. Анда 5 нче гимназиядә укучы 14 яшьлек кыз ут ачкан. Ике бала һәлак булган (берсе – ут ачучы кыз, ул үз-үзенә кул салган), 5есе яраланган.

96 ФАП яңартылган

Татарстанда «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының сырхауханәләрне яңарту буенча федераль программасы нигезендә 96 фельдшер-акушерлык пункты (ФАП) төзекләндерелгән. Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте мәгълүматлары буенча, әйтик, Актаныш районы үзәк хастаханәсенең – 8, Балык Бистәсе – 8, Апас, Биектау, Зәй районнарының – 7шәр, Әлмәт, Яңа Чишмә, Нурлат районнары үзәк хастаханәләренең 5әр ФАПы яңартылган. Аларның барысында да уңайлыклар тудырылган.

Эшчеләр фельдшер-акушерлык пунктларының идәнтүшәмнәрен буяган-бизәгән, яңа ишек-тәрәзәләр урнаштырган, сантехника, плиткаларны алыштырган, су һәм җылылык белән тәэмин итү системаларын яңарткан.

Исегезгә төшерәбез: «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты медицина ярдәмен үстерү һәм чирләрне кисәтүне камилләштерүгә юнәлдерелгән. Илкүләм проектлар, 2019 елдан бирле, Президент Владимир Путинның «Май ае указлары» нигезендә гамәлгә ашырылып килә. Алар «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «Экология», «Демография» кебек мөһим юнәлешләрне үз эченә алган.

Сак бул!

Утка тотылма!

Көннәр салкынайткач, күбебез электр җиһазларын куллана. Бер яктан җылыта, икенче яктан куркыта бу өстәмә чаралар. Җылыткычларны, мичләрне сак кулланмасак, ут-күз чыгуы да ихтимал. Татарстанда, салкыннар башлангач, берничә йорт янды инде.

Күптән түгел Кукмарада булган янгын кеше гомерен дә алып китте. Галимә һәм Зиннур Корбангалиевлар йортында килеп чыккан янгында хуҗабикә вафат булды. Уллары Илназ әтисен коткарып калса да, әнисен уттан алып чыгарга өлгермәгән. Гаилә башлыгы әлегә хастаханәдә дәвалана, Галимә

tatarstan.ru

апаны 11 декабрьдә җирләгәннәр. Сүз уңаеннан, әлеге гаилә, былтыр Яңа ел бәйрәменә өйләрен матур итеп бизәп, беренче урынны алган булган. Ә менә быел йортлары көлгә әйләнде. Кукмара районының 117 нче коткару бүлеге хезмәткәре Илмир Хәбибрахманов әйтүенчә, янгынның сәбәбе – электр җиһазларын дөрес кулланмау.

– Корбангалиевлар ул көнне гирляндаларын яндырмаганнар. Әмма күрәчәк үзенекен эшләгән, – ди коткаручы. – Салкыннар башлануга, кешеләр җылыткыч куллана башлады. Кайда салкын – шунда электр приборлары куялар. Өстәл аслары да калмый, хәтта машиналарны да шулай җылыталар. Шунлыктан ут кабу очраклары кабатланып тора.

Илмир Хәбибрахманов әйтүенчә, Корбангалиевлар тавык кетәклегенә җылыткыч куйган булган. Ут шуннан чыккан. Аннары өйләренә үрмәләгән.

– Безгә янгын хакында хәбәр соң килде. Бераз алданрак белгән булсак та, әле коткара алыр идек. Ул көнне 38 градус салкын иде. Урамда кеше дә булмаган, янгынны соң күргәннәр. Шуңа да без барлык кешеләргә салкыннарда аеруча сак булырга киңәш итәбез, – ди ул.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе матбугат үзәге җитәкчесе Андрей Родыгин сүзләренчә, ел башыннан республикада 4633 янгын очрагы теркәлгән. 187 кеше зыян күргән. 129ы янып үлгән, шуларның сигезе – балалар. 381 кешене янгыннан коткара алганнар.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз



Валерий ЗОРЬКИН, Россия Конституция суды Рәисе:

Илдә коррупция халык тормышы һәм җәмгыять өчен куркыныч төс алды. Гәрчә хакимият һәм җәмгыять әлеге проблеманың ни дәрәҗәдә зур булуын аңласа да. Минем уйлавымча, бу өлкәдә барлык мөмкинлекләр дә файдаланылмый. Аңа каршы көрәш – мөһим мәсьәлә. Чөнки коррупция таркалу һәм җимерелүгә китерә.

(«РИА Новости» басмасыннан)

БӘЙРӘМ ТУРИЗМЫ

Туристлар Яңа елда Россиянең кайсы шәһәрләренә юл тотачак? OneTwoTrip хезмәте шуны ачыклаган. Шунысын да әйтергә кирәк: сораштыруда катнашучыларның 70 проценттан артыгы үз шәһәрендә булачагын әйткән.



Авыручылар арта

Татарстанда коронавирус белән чирләүчеләр саны артканнан-арта. 4–10 декабрь аралыгында авыру йоктыруның 1371 очрагы ачыкланган.

Пандемия башланганнан бирле республикада чир йоктыруның барлыгы 213249 очрагы теркәлгән. 208825 кеше савыккан. Кызганыч, 2010 сырхау вафат булган.

Тулаем Россиягә килсәк, узган атнада 107174 кеше авырган. 9451 сырхау хастаханәгә озатылган. Бер атна эчендә 148 сырхау (пандемия башланганнан бирле – 400864) ковидтан үлгән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЕВРОПА РЕЦЕССИЯДӘ

Bloomberg агентлыгы, үз икътисадчыларының фикеренә таянып, Еврозонаның пандемиядән соң беренче тапкыр рецессиягә кереп батуын игълан итте. Моны кризисның башлануы хакында рәсми белдерү дип кабул итәргә була. Валюта союзына кергән 20 илнең гомуми эчке тулай продукты быелның өченче кварталында 0,1 процентка кимегән. Дүртенче кварталда да җитештерү шуның кадәр түбәнәер дип көтелә. Исегезгә төшерәбез: җитештерүнең ике квартал рәттән түбәнәюе рецессия дип атала. Ул эшсезлек артуын, бюджет кризисын, бурычларның түләнмәячәген вәгъдә итә. Барлык бизнесның процентлы кредитлар белән эш итүен истә тотсак, җитештерүнең кимүе генә түгел, хәтта җитәрлек артмавы да әҗәтләр кризисын китереп чыгара. Кредит алучылар башта процентларны яңа кредитлар белән түләп бара, аннан соң, күтәрелеш булмаса, дефолт игълан итәргә туры килә. Гадәттә рецессия шартларында фонд базары да җимерелә, бу өстәмә финанс югалтуларына китерә. Ихтыяҗ кимү сәбәпле, бәяләр, бигрәк тә чимал бәяләре төшә. Соңгы бер-ике атнада без нефть бәясенең, ОПЕК+ яңа кыскартулар игълан итүгә карамастан, сизелерлек түбәнәюен күзәтәбез. Нефть картеленә кермәгән илләр кара алтын чыгаруны арттырып та, аның бәясен түбәнгә этә. АКШ соңгы көннәрдә планетадагы бердәнбер нефть державасына әверелде: көнлек чыгаруны 13,2 миллион баррельгә җиткерде.

Әлегә Европада 2024 елның беренче кварталында тыйнак кына күтәрелеш башланыр дип өметләнәләр. Әмма процент ставкаларының югары торуы, аларны күтәрүгә карамастан, инфляция үсеше дәвам итү өметләрнең кысырлыгын вәгъдә итә.

Рецессия – йогышлы күренеш, зур бер икътисад төбәге аның белән чирли икән, ул бар планетага тарала. Җир шарындагы икенче зур икътисад булган Кытай икътисадында проблемалар арта. Күк асты илен беренче тапкыр чит ил инвесторлары ташлап кача. Бу күселәрнең батучы корабны ташлап качуын хәтерләтә.

Кытайда дуңгызчылык тармагы инде кризис хәлендә. Дуңгыз ите җитештерүче ун иң эре компаниянең бурычы ел башыннан сентябрь азагына кадәр 13 процентка үскән. Дуңгыз асраучыларның тулаем бурычы 200 миллиард юаньга (2,5 триллион сум) җиткән. Кытайлар, импортны алыштырабыз дип, дуңгызларның баш санын нык арттырганнар һәм ит бәясе, 15 процентка төшеп, үзкыйммәттән дә кимегән.

Зур икътисадлар әлегә эмиссия – акча басу ярдәмендә дефолттан кача. Бу инфляция булып кайтаваз бирә. Африка иле Эфиопия долларлы облигацияләренә процентлар түләүдән туктарга һәм дефолт игълан итәргә җыена.

Россиядә

ИКЕ ТӨРЛЕ ИНФЛЯЦИЯ

Дөньякүләм кризис Россиядә дә үз эзен тирән сала. Россия нефтенең бәясе түшәм бәядән дә түбәнгәрәк китте. Кытай бездән корыч сатып алуны өч тапкыр киметте дигән хәбәрләр дә күренде. Бюджет дефицитын үстерә торган нәрсәләр болар. Әмма федераль хөкүмәт аптырамый: бюджетны тутыруның ике ышанычлы юлын – девальвация һәм инфляцияне актив файдалана. Сумның арзанаюы базарлар өчен начар, казна өчен яхшы. Моны һәркем белә. Инфляция шулай ук салымнарның сумнардагы күләмен үстерә. Шуңа күрә бюджет турында сөйләгәндә, без фанфаралар кагабыз, базарга чыкканда акча янчыклары зар елый.

Инфляция, дигәннән, Росстат аны 7,5 процентка җитте, ди. Ул санга Үзәк банкта да ышанып ук бетмиләр бугай. Барлык аналитиклар да, бу җомгада Үзәк банк утырышында төп ставка күтәреләчәк, диләр. Күпчелек 16 процент турында сүз алып бара, 17 процент, 15,5 процент турында әйтүчеләр дә бар. Төп ставка ул – Үзәк банкның коммерция банкларына биргән кредитының проценты. Банклар шул процент белән акча ала да бизнеска күпкә югарырак процент белән әҗәт биреп, акча эшли. Гадәттә төп ставка белән инфляция бер тирәдәрәк бии.

РОМИР агентлыгы инфляцияне башкача исәпли. Кибетләрдәге уртача чек күләменнән чыгара. Менә шул чек күләме 8 атна рәттән арта икән инде. Үткән елның шушы вакыты белән чагыштырганда уртача чек 145 сумга үскән. Бу 21 процентка тигез. Бу иң күп сатып алына торган товарлар бәясе шул күләмдә үскән дигәнне аңлата. Росстат та алдашмый, ул барлык товарлар бәясеннән чыгара инфляцияне. Әйтик, игәү бәясе күтәрелмәскә дә мөмкин. Күтәрелсә дә, төшсә дә, ул безнең янчыкны игәүләми барыбер, чөнки без аны ике-өч елга берне сатып алабыз. Ә йомырка, ит, икмәк, сөт кебек көн саен кирәкле товарлар акча янчыгын сыгып кына ала.

Ришвәтчелек өчен 5 ел төрмә шулпасы эчеп чыккан элекке икътисадый үсеш министры Улюкаев халыкка акча җыймаска, күп итеп ашарга-эчәргә киңәш бирә. Аның киңәше акча депозитта да барыбер яначак, иң яхшысы тотып калыгыз дигәнне аңлата. «Союзмолоко» генераль директоры Артем Белов, сөт тармагында җитештерүнең үзкыйммәте – 16 процентка, эшкәртүнеке 15 процентка кадәр артты, ди. «Үзкыйммәт артканда, бәяләр нишли?» – дигән риторик сорау калкып чыга. Шулай булгач, Улюкаев киңәше дөрес: ашап булганда, ашап калыгыз.

tatarstan.ru

Дәүләт Советында 14 яше тулган балаларга паспортлар тапшыру тантанасы узды. «Мин – Россия гражданины» тантанасы Россия Конституциясе көненә (кичә илнең Төп Законына 30 «яшь» тулды) багышлап уздырылды. Балаларга паспортларны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды.
Тантанага төрле районнардан 20 укучы – укуда, олимпиада, спорт ярышларында зур уңышларга ирешүчеләр, мәктәпнең иҗтимагый тормышында актив катнашучылар җыелды. «Россия гражданины паспорты белән тормышның яңа – аңлы этабына керәсез, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, укучыларга мөрәҗәгать итеп. – Сезгә хәзер, гражданин буларак – аерым таләпләр. Бурычларыгыз, шул ук вакытта хокукларыгыз да барлыкка килә. Белемле, тәрбияле, актив булып үсүегезне телим!»

РӘСМИ ТАТАРСТАН

Илленче утырышны көтәбез

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының илленче утырышы 18 декабрьдә үткәреләчәк. Кичә парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Анда 19 мәсьәләне, шул исәптән 7 республика законы проектын һәм Дәүләт Советының кайбер карарларын карап тикшерү күздә тотыла.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Президиум әгъзаларын һәм утырышта катнашучыларны Россия Конституциясенә 30 ел тулу уңаеннан котлап, дәүләт өчен бик авыр вакытта кабул ителгән Төп Законның, күпмилләтле Россияне эзлекле үстерү максатында, җәмгыятьне берләштерүен әйтте.

Шуннан соң парламент башлыгы соңгы вакытларда республикада булып узган мөһим вакыйгалар турында кыскача гына сөйләп үтте. Фәрит Мөхәммәтшин иң элек Федерация Советының 7 декабрьдә ил Президентын сайлауны киләсе елның 17–19 мартына билгеләвен искәртте. Ул Татарстанда яшәүчеләрнең, гадәттәгечә, зур активлык күрсәтеп, Владимир Путин кандидатурасын бертавыштан хуплаячагына ышаныч белдерде.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина Президиумга парламентның илленче утырышын 18 декабрьдә уздыруны тәкъдим итте. Ул парламент комитетларының көн тәртибенә 19 мәсьәләне, шул исәптән Татарстанның 7 закон проектын кертүен билгеләп үтте.

Илленче утырышта шулай ук 2024 елга Дәүләт Советында закон проектлары буенча эшнең үрнәк планын, Дәүләт Советының Россия төбәкләре, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең үрнәк планын кабул итү күздә тотыла.

Фәрит Мөхәммәтшин Дәүләт Советының быелгы соңгы утырышында, гадәттәгечә, парламентның еллык эшчәнлеге турында сөйләячәк.

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

МИЛЛӘТ БАЙЛЫГЫ

Кем без, безнең тарихыбыз, гореф-гадәтләребез нинди, асылыбыз нидән гыйбарәт? Республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы менә шушы сорауларга җавап эзләүгә багышланган булган икән. Җаваплар да озак көттермәс дип өметләник.

tatarstan.ru

2023 ел азагына якынлаша. Димәк, республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы да. Республиканың мәдәният министры Ирада Әюпова:

– Мәдәнияттә нәтиҗә икенче көнгә үк була алмый, күпмедер вакыт узарга тиеш. Моны һәрвакыт истә тотарга кирәк. Ниятләнгән барлык эшләрне дә быел башкарып бетерү дигән максат юк иде. Бу ел – бик күп башлангычларга старт. Димәк, елның нәтиҗәләре бүген үк күзегезгә күренмәсә, аптырыйсы түгел, – диде.

Нәтиҗәнең берсе шәйләнә инде. Ирада Әюпова сүзләренә караганда, хәзер миллилек көнкүрешкә дә үтеп керде (аяк киемнәре, көнкүреш җиһазлары һ.б.).

– Традицион һөнәрчелекне заманча көнкүрешкә җайлаштырып, саклап калу һәм киләчәк буынга тапшыру даими рәвештә эшләнелә торган эш булса да, быел без бик мөһим нәтиҗәгә килдек: Рәисебез Рөстәм Миңнеханов тарафыннан һөнәрчелек үзәген булдыру турында карар кабул ителде, – диде министр.

Узып баручы елның төп мәгънәсе исә тамырларыбызны барлау һәм тану булгандыр. Ирада Әюпова да шулай ди.

– Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының төп мәгънәсе – үзебезнең тамырларыбызны тану, дип әйтсәк, иң дөресе булыр. Кем без, каян килдек, безнең тарихыбыз, гореф-гадәтләребез нинди – һәр кеше үзе өчен шуны аңласа иде. Күп кенә проектларыбыз шушы үзаңны формалаштыруга багышланган да, – диде министр.

Бу ел дәвамында тормышка ашырылучы чараларны журналистлар да яктыртып барды (шул исәптән «ВТ» да). Игътибарлы укучы аларны күз уңыннан җибәрмәгәндер, шуңа күрә кайда нинди бәйрәм оештырылганын санап тормабыз.

Берсенә тукталыйк әле шулай да.

– Бу елның төп үзенчәлеге булып республика районнары арасында «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы тора. 31 марттан алып 31 октябрьгә кадәр Казанның төрле мәйданчыкларында 43 район үз программасын тәкъдим итте, – диде Ирада Әюпова.

Конкурсны 90 мең кеше онлайн караса, районнарның милли коды белән 33 мең кеше тамаша залына килеп танышкан. Белмәгән булсагыз, белегез: «Татарстанның мәдәни башкаласы» исемен Арча йөртә.

Кәсепчелеккә яңадан әйләнеп кайтыйк. Татарстанда халык сәнгате һөнәрчеләрен барлаячаклар. Үзенә күрә – җанисәп. Ирада Әюпова аларны «традицияләрне саклаучылар» дип атады.

– Теге яисә бу һөнәрне, кәсепне саклаучы останы күрмибез, белмибез икән без. Әйтик, авылда берәү үзе өчен челтәр үрә, әмма аны сатуга чыгармый. Тик ул бит традицияне саклаучы булып санала. Ул бит – оста, ул бу кәсепне белә, – диде министр. – Безгә андый кешеләрне барларга кирәк. Бу әле – эшнең беренче этабы гына.

Аяк астындагы алтынны күрә белергә кирәк шул. Монысы да – Ирада Әюпова сүзе. Ә милләтнең алтыннары җитәрлек.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

- Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында **5000**нән артык чара оештырылган.
- **2023** елда Татарстанда «Мәдәният» илкүләм проектын тормышка ашыру өчен **1,595 млрд** сум акча юнәлтелгән. Федераль бюджеттан – **692,2 млн**, Татарстанныкыннан **393,2 млн** сум акча тотылган. Өстәмә рәвештә республика тагын **17,9 млн** сум акча бүлеп биргән. Сүз уңаеннан, әлеге проект кысасында быел Татарстан авылда сафка баскан объектлар саны буенча лидер булып танылган.

ЭТЛӘР ТЫНГЫЛЫК БИРМИ

Нәтиҗә

Этләр приютын тотар өчен 100 млн сумга кадәр акча кирәк. Ә бер этне анда яшәтү көненә 150 сумга төшә. Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигый байлыклардан файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында чираттагы тапкыр сукбай этләр проблемасын күтәрделәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, әлеге мәсьәлә турында фикер алышулар башланганчы, Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов ветеринария тармагы буенча елга нәтиҗә ясады.

– Быелгы ел гади булмады, – диде ул. – Беренчедән, санкцияләр аркасында ветеринарларның кайбер төр вакциналары һәм препаратлары юк. Әлеге проблемалар федераль һәм республика дәрәҗәсендә хәл ителә. Ләкин авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре бу мәсьәләдән чыгу юлын табарга тырыша. Кайбер төр вакциналар үзебезнекенә алыштырылды, вакциналарның эш схемасы кире каралды.

Икенчедән, ветеринарларга авырулар буенча вазгыять тә тынгылык бирми. Быел Россиядә кош гриппының 75 очрагы теркәлде. Аларның 34е – Идел буе федераль округында, 6 кош фабрикасы зыян күрде. Бу хәлләр Татарстанны да читләтеп узмады. Башка авырулар да тик тормый. Әйтик, дуңгызларда Африка чумасының 94 очрагы теркәлгән. Иң соңгы зарарлану очрагы 1 декабрьдә Удмуртиянең Грахов районында булган. Ә бит бу Татарстаннан – нибары 20 чакрым, ә бик зур «Камский бекон» дуңгызчылык комплексыннан 55 чакрым ераклыкта гына. Болардан тыш, соңгы көннәрдә телдән төшмәгән бруцеллез авыруы да аграрийларның да, ветеринарларның да тынычлыгын алды.

– Безнең республикада бу авыруның 1992 елдан бирле булганы юк иде. Идел буе федераль округында без бер утрау кебек кала килдек. Быел чир безне дә аямады. Бруцеллезның ике очрагы теркәлде. Әлеге вакытта «Тукай» хуҗалыгында авыру учагын бетерү буенча эшләр бара. Мәсьәлә җиңел түгел, терлекләр күп, ләкин якын арада барлык малларны да юк итеп бетерәчәкбез, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Илдә Себер түләмәсе, нодуляр дерматит кебек куркыныч авырулар да очраштыргалый. Бу уңайдан баш ветеринар барлык төр хайваннарга да профилактика чаралары уздырылуын һәм вакцина ясалуын әйтте.

Утырышта күтәрелгән икенче төп мәсьәлә сукбай этләргә кагыла иде. Ни кызганыч, күпме генә сөйләшсәк тә, фикер алышсак та, әлеге проблема чишелеш таба алганы юк әле. Алмаз Хисаметдинов сүзләренчә, быел хуҗасыз этләрне аулау һәм асрау өчен бюджеттан 75,4 млн сум акча тотылган. Киләсе елга бу эшләргә күбрәк акча бүлеп биреләчәк: 88,3 млн сум. Аның 29 млн сумы агрессив этләрне карап тотуга китәчәк. Әлеге вакытта Татарстанда эшли торган 19 приютта 3 мең эт яши. Аларның икесе муниципаль булса, калганнары – шәхси. Тагын бер приют Чаллыда төзелә.

– Приютлар буенча безнең сорауларыбыз күп. Бүген төбәкләргә сукбай этләр буенча үзләренә хәл итү мөмкинлеген бирделәр, һәм кайберләрендә тәңгәлләштерү, теркәү тәртибен билгеләделәр. Әйтик, Якутиядә этләрне үтерү турында закон кабул иттеләр. Ләкин беренче дулкыннар узар өчен күпмедер көтәргә кирәк, прокуратура мондый карар кабул ителгән субъектларны тикшерә, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Аның сүзләренчә, республикада ел саен якынча 20 мең тирәсе эт аулана. Ә приютны СанПиНның барлык кагыйдәләре буенча төзү өчен, якынча 100 млн сум акча кирәк. Аларны карап тоту да арзан түгел: әгәр 4–5 ел элек бер этне карап тоту 107 сум булса, хәзер бу 150 сумга җитә.

– Бу бик кыйммәт. Безгә ел саен моның өчен акча бүлеп бирергә туры киләчәк. Шуңа күрә барыбызга бергә нинди дә булса карар кабул итәргә кирәк, – диде баш ветеринар.

Тагын бер мөһим проблема бар, ул да булса – этләрне теркәү. Әлеге вакытта республикада 110 мең эткә вакцина ясалган, нибары 14 меңе генә теркәлгән. Хуҗаларына уңайлы булсын өчен, Дәүләт хезмәтләре порталында да теркәлү мөмкинлеген булдырганнар иде, тик мәҗбүриләү булмагач, бу эш бик акрын бара.

Комитет рәисе Азат Хамаев та сукбай этләрнең иң борчыган проблемаларның берсе булуын белдерде.

– Әгәр без хайваннарны мәҗбүри теркәү тәртибен кертмибез икән, сукбай этләр алга таба да ишәячәк кенә. Ел дәвамында бу мәсьәләне хәл итмәсәк, сукбай этләр тешләгән, үтергән кешеләр тагын да булачак, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«РЕСПУБЛИКА – ТОТРЫКЛЫ ТӨБӘКЛӘР ТӨРКЕМЕНДӘ»

Уртак акча. Атна ахырында Татарстан Финанс министрлыгы, Салым федераль хезмәте һәм Федераль казначылыкның республикадагы идарәләренең уртак утырышында узып баручы елга йомгак ясап, киләсе бурычлар турында сөйләшәчәкләр. Республика бюджеты ни хәлдә? Утырыш алдыннан Татарстан финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИН «ВТ» хәбәрчесенә шул хакта сөйләде.

:: Радик Рәүфович, узып баручы ел финанс-икътисадый яктан бик үзенчәлекле булды. Сәяси мәсьәләләр бөтен дөньяның, шул исәптән илебезнең дә икътисадына кискен йогынты ясады. Беренче кварталда вазгыять аеруча катлаулы иде. Нефть һәм нефть продуктларына, химия производствосы продукциясенә бәяләр төште. Бик күп хуҗалык элемтәләре өзелде, җитештерелгән товарлар логистикасы җимерелде, күп кенә предприятиеләр яңа товар җибәрүчеләр һәм кулланучылар эзләргә мәҗбүр булды. Мөгаен, боларның барысы да бюджет үтәлешенә турыдан-туры йогынты ясагандыр. Шул хакта сөйләп үтсәгез иде.

– Агымдагы елда икътисадыбыз кичергән хәлләрне дөрес бәяләп үттегез. Өстәп шуны әйтә алам: 2023 елның башында, ягъни беренче өч-дүрт айда бюджет үтәлеше аеруча кыен барды. Нефть, химия производстволары продукциясенә бәяләр төште, шул ук вакытта инфляция көчәйде. Дистәләрчә еллар буе булдырылган хуҗалыкара элемтәләрнең өзелүе өстәмә кыенлыклар тудырды.

Предприятиеләргә комплектлау детальләренең аерым төрләрен җитештерүне мөстәкыйль үзләштерергә, җитештерүнең бөтен циклын һәм технологик чылбырны өр-яңадан диярлек оештырырга туры килде. Зур кыенлыклар сизә башладык: чөнки бюджет керемнәре планлаштырылган чыгымнарны тулысынча финанслауга җитми башлады. Муниципалитетлар һәм бюджет акчаларын баш бүлүчеләр белән берлектә аерым тармаклар, барлык төр бюджетлар буенча кирәкле исәп-хисапларны башкарып, кайбер чыгымнарны финанслауны дүртенче кварталга күчерергә кирәк, дигән карарга килдек. Шул ук вакытта хезмәт хакына, халыкка социаль ярдәмгә, бюджет учреждениеләрен, ягъни балалар бакчаларын, мәктәпләрне, мәдәният, сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт объектларын тотуга чыгымнар бер тиенгә дә кимемәде. Барлык кыенлыкларны аңлап, бюджет кризисыннан чыгарга ярдәм иткән күпчелек муниципаль берәмлекләргә һәм министрлыкларыбызга зур рәхмәт!

Бюджеттагы кыенлыкларны нигездә Татарстан Рәисенең, аның командасы, предприятиеләр һәм муниципаль берәмлекләрнең зур тырышлыгы нәтиҗәсендә җиңеп чыктык. Җитештерүдәге җитешсезлекләрне бетерү, логистиканы җайга салу, продукция җитештерү күләмнәрен көн саен тикшереп тору, хезмәт хакының түләнүен тәэмин итү нәтиҗәсендә күп мәсьәләләр уңай хәл ителеп, бюджетка түләүләр керде.

Саннардан күренгәнчә, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга керемнәр керү динамикасы уңай.

Тулаем алганда, керемнәр 561,2 млрд сум керәчәк. Шул ук вакытта салым һәм салым булмаган керемнәр 476,0 млрд сум тәшкил итәчәк. 11 айда тупланма бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәрен җыю күләме буенча Россия субъектлары арасында Татарстан Республикасы – алтынчы урында.

:: Сез 2023 елда күтелгән бюджет үтәлешенең гомуми нәтиҗәләрен атап уздыгыз. Керемнәрнең һәм чыгымнарның аерым юнәлешләре буенча ел йомгаклары ниндирәк?

– Узган еллардагы кебек үк, тупланма бюджетта шактый зур өлешне табышка салым, физик затлар керемнәренә салым, акцизлар, оешмалар мөлкәтенә салым алып тора. Алар барысы бергә бюджетның үз керемнәренең 84 процентын тәшкил итә.

Бүген шуны ышандырып әйтергә мөмкин: табышка салым бюджетка рекордлы күләмдә – 179,6 млрд сум күләмендә керәчәк. Шуның 47 процентын нефть чыгару һәм нефть эшкәртү, химия һәм нефть химиясе предприятиеләре тәэмин итә.

Шулай ук әһәмияте ягыннан икенче урындагы физик затлар керемнәренә салымны туплау да тәэмин ителә. Анысы узган елдагыга караганда 22 процентка артып, 140 млрд сум күләмендә күтелә.

Мөлкәткә салым. 1 декабрьгә кадәр түләнергә тиешле булган әлеге салымның күп өлеше бюджетка керде инде. Форсаттан файдаланып, салымны вакытында түләүчеләргә рәхмәт белдерәсем килә.

Татарстан Республикасының тупланма бюджеты чыгымнары 602 млрд сум булыр дип күтелә. Ел башына калган бюджет акчасы һәм тупланган керемнәр бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакларын үз вакытында тулысынча түләү, барлык дәрәҗәдәге бюджетларның планлаштырылган чыгымнарын җитәрлек күләмдә финанслау мөмкинлеге бирә.

:: Укучыларыбызны иң кызыксындырган сорауларның берсе – республиканың дәүләт бурычы. Хәзерге вакытта ул нинди хәлдә, алда ни көтәргә?

– Чыннан да, быел федераль бюджеттан яңа кредитлар алынды. Инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруга һәм гомуми файдаланудагы пассажирлар транспортын сатып алуга Федераль казначылык хезмәтеннән республикага 10,4 млрд сум акча күчерелде.

Моннан тыш бюджет хисабына 4,3 млрд сумлык дәүләт гарантиясе бирелде. Ул агымдагы елның ноябрендә закон нигезендә расланды. Бу акча юл төзелешенә тотыла.

Шулай итеп, дәүләт бурычы 127,6 млрд сумга җитте. Бурычның зур өлеше озак вакытлар дәвамында түләү бәрабәренә алынды.

Шул ук вакытта кредитлар буенча республика бурычының бер өлешен гамәлдән алу эше дәвам итә. Агымдагы елда, республиканың элегрәк реструктурлаштырылган 7,9 млрд сумлык кредит бурычын гамәлдән чыгару турында федераль дәрәҗәдә карар кабул ителде. Бу, федераль дәрәҗәдә хупланып, 2022 елда кайбер яңа инвестиция проектларын тормышка ашырудан федераль бюджетка кергән салым кереме күләменә туры килә.

Бурычның билгеле бер дәрәҗәдә артуына карамастан, республика финанс базарларыннан кредит алу мөмкинлеген карамый. Россия Финанс министрлыгының методикасы нигезендә, республика бурычны түләүдәге тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган төбәкләр төркеменә керә.

:: Узып баручы ел ахырына һәм киләсе финанс елына Татарстан Финанс министрлыгы үзенә нинди төп өстенлекле бурычларны билгеләде?

– Беренчедән, әлбәттә, агымдагы ел ахырына кадәр барлык дәрәҗәдәге бюджетларның керемнәр һәм чыгымнар буенча сыйфатлы үтәлешен тәэмин итү бу.

Икенчедән, киләсе ел бюджетын үтәүгә әзерлек. 2024 елга республика бюджеты 28 ноябрьдә кабул ителеп, имзаланды. Хөкүмәтнең аны тормышка ашыру турында карары булдырылды.

Расланган бюджет кысасында чыгымнар сметалары, дәүләт программалары эшләнеп, барлык бюджет чыгымнарын финанслауны билгеләүче бюджет росписе расланачак.

Бер үк вакытта хәзер 956 җирле бюджет раслана. Бу эш 20 декабрьгә кадәр тәмамланырга тиеш.

Шулай итеп, республика бюджеты һәм җирле бюджетлар чыгымнары киләсе ел гыйнварының беренче эш көннәреннән үк өзлексез финансланачак.

:: Әңгәмә азагында укучыларыбызга теләкләрегезне әйтеп үтсәгез иде.

– Беренче чиратта, Җирдә тынычлык булсын, саулыктан аермасын. Икенчедән, предприятиеләребез тотрыклы эшләсен. Шулай икән, ел дәвамында барлык бюджетларны үтәү һәм республика халкының тормышын яхшырту өчен расланган чараларны финанслау мөмкинлеге булачак.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илленче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илленче утырышын 2023 елның 18 декабрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 12 декабре
№ 2265-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илленче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илленче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 509-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 512-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 511-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 498-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 510-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 508-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында.
11. Ганиев Илшат Газыйм улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты составындагы үзгәреш турында.
13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның декабренә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
14. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
15. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
16. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 481609-8 номерлы федераль закон проекты турында (полиция органнары һәм контроль (күзәтчелек) органнары вәкаләтләре кабатлануны бетерү хакында).
18. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү турында».
19. 2023 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 12 декабре
№ 2266-VI ДС

---

kzn.ru

ИСӘНМЕ, ЯҢА... БӘЯ!

КАЗАНДА ЮЛДА ЙӨРҮ БӘЯСЕ 42 СУМГА КАДӘР АРТА

Киләсе елның 1 гыйнварыннан башкалада җәмәгать транспортында йөрү бәясе кыйммәтләнәчәк. Акчалата түләгәндә, юл хакы, берьюлы 6 сумга артып, 42 сумга җитәчәк. Яңа ел алдыннан килеп ирешкән әлеге хәбәр ике якның да кәефен кырды: гади халык, җәяү йөрергә калмасак ярый, дип уфтанса, пассажир йөртүчеләр юлда йөрү бәясен тагын да күбрәк арттыруны сораган булган. Юл ник кесәгә суга?

– Безнең гаиләдә генә дә җәмәгать транспортында йөрүгә аена 5–6 мең сум чамасы акча китә, кем әйтмешли, бу – яшәү минимумының яртысы, – ди Казанда яшәүче Резидә Мәрданова. – Ирем – рульдә, ул эшкә иртә чыгып киткәнлектән, миңа һәм улыма йөрергә автобус кына кала. Җәмәгать транспортына көнгә ике генә утырсаң да, атнага 450–500 сум акча кирәк. Улым җиденче сыйныфта укый, мәктәпкә кадәр дүрт-биш тукталыш. Җылы, коры вакытта иптәшләре белән җәяү йөрсәләр, кышкы суыкта аңа да автобуска яки троллейбуска утырырга туры килә. Өстәвенә бассейнга тренировкаларга йөри. Гаиләдә баланың юлга айлык чыгымнары 3 мең сум тирәсе тәшкил итә. Яңа елдан соң әлеге төр түләүләр тагын да артачак, димәк. Бәя күтәреп кенә калмыйча, халыкка күрсәтә торган хезмәтнең сыйфатын да яхшыртсыннар иде: автобуслар иске, тукталышта озак көтәргә туры килә. Без нәрсә өчен түлибез?

Шәһәрнең җәмәгать транспорты эшчәнлегеннән зарланучылар тагын да күбәер, мөгаен. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты утырышында киләсе елга яңа бәяләрне расладылар.

2024 елның 1 гыйнварыннан Казанда җәмәгать транспортында йөрү бәясе акчалата түләгәндә – 42 сум, карта белән түләгән очракта 38 сум булачак. Электрон транспорт картасы белән йөрү хакы 38 сум тәшкил итәчәк. Йөз тапкыр баруга исәпләнгән электрон транспорт картасыннан файдаланучыларга исә билет бәясе 28 сумга төшәчәк. Сүз уңаеннан, быел Татарстан башкаласында җәмәгать транспортында йөрү бәясе акчалата түләгәндә – 36 сум, ә карта белән 35 сум тора. Киләсе елда тарифлар уртача 9,5 процентка артачак.

Дәүләт комитетының бүлек җитәкчесе Гаяз Миңнебаев сүзләренә караганда, тарифлар үзгәрүгә җитди сәбәпләр бар.

– Киләсе елда электр энергиясенә бәяләр – 9,1, ягулык-майлау материалларына 15 процентка артачак дип фаразлана. Автобус һәм троллейбусларга кирәкле шиннар 12 процентка кыйммәтләнде. Яңа тарифларда тармакта эшләүчеләрнең хезмәт хакларын күтәрү, автопаркка 25 яңа троллейбус сатып алуга бәйле чыгымнар да исәпкә алынды, – диде ул.

Утырышта катнашкан Казан Башкарма комитеты җитәкчесенең транспорт буенча урынбасары Илдар Шакиров сүзләренә караганда, яңа тариф һәр яктан да расланган.

– Бу – пассажир йөртүчеләр сораганнан азрак, әлбәттә, – диде ул, турысын ярып. – Әмма яңа бәягә бәйле бернинди каршылык та юк. Аны билгеләгәндә, тотылган чыгымнар исәпкә алынган, – диде ул.

Казан юлларында 1037 данә транспорт чарасы, шул исәптән 749 автобус, 182 троллейбус һәм 102 трамвай хезмәт күрсәтә.

– Автопаркның 35 процентттан да күбрәге ун «яшь»тән дә өлкәнрәк. Моннан тыш, тармакта кадрлар кытлыгы күзәтелә. Бүген 1,5 мең хезмәткәр, шул исәптән 800 йөртүче җитми, – дип сөйләде Илдар Шакиров.

Яңа тарифларны билгеләгәндә, Казанга ташламалы лизинг программасы буенча 250 «НефАЗ» сатып алуга бәйле чыгымнар да кермәгән. Илдар Шакиров сүзләренә караганда, ташламалы программа киләсе елның февраленә кадәр генә гамәлдә. Тик КАМАЗда ул вакытка кадәр автобусларны җитештереп бетерергә өлгермиләр. Шуңа күрә хәзер программаны озайту мөмкинлеге турында сөйләшүләр алып баралар. Урынбасар якынча санап та күрсәтте: моннан берничә ел элек «НефАЗ» автобусы 10–12 миллион сум торса, хәзер ул 18 миллион сумга җитә. Ә бер машина өчен айлык лизинг түләве 300 мең сум тәшкил итә. «Пассажир ташучылар бу кадәр чыгымны күтәрә алмый, билгеле. Шуңа күрә республика, шәһәр ярдәменә өметләнәбез», – диде Илдар Шакиров. Чыдасын кесә…

Эльвира ВӘЛИЕВА

Утка тотылма!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

ЯНГЫН ЧЫКМАСЫН ӨЧЕН НИШЛӘРГӘ?

➤Һәр электр җиһазының үз куллану вакыты бар, уртача алганда, бу 10 елны тәшкил итә. Аннан да артык кулланмаска кирәк.

➤Җылыту приборын даими күзәтеп торырга, вакытында ремонтларга, сафтан чыккан булса, алмаштырырга кирәк. Электр җылыткычларын төнгә кабызып калдырмагыз. Аларны әйберләр киптерү өчен файдаланмагыз.

➤Лак-буяу материаллары, эреткечләр, тиз янып китүче сыекчалар булган, тиз янып китә торган чүп-чар булган җирдә җылыткычтан файдаланмагыз.

➤Электр чыбыгына авыр әйберләр, җиһазлар куймагыз, югыйсә җылыткыч артык нык кызарга мөмкин. Электр чыбыкларын келәмнәр һәм башка өслекләр астыннан сузмагыз.

➤Газ плитәсе кабызып, өй җылытмагыз!

Яңа ел алдыннан күбебез чыршы бизи, гирляндалар элә. Урамнан да йортларын утлар белән матурлаучылар бар. Әмма арзанлы гирляндалар, суыкка түзә алмыйча өзелеп, ут чыгара ала. Шуңа күрә, артык салкын көннәрдә аеруча сак булырга, электр приборларының төзеклегенә инанырга кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белеп тор!

Татарстанда 25 нче декабрьдән янгынга махсус каршы режим гамәлгә керәчәк. Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрендә пиротехника куллануга чикләүләр киләсе елның 8 гыйнварына кадәр дәвам итәчәк. Тиешле карарга Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин кул куйган. Документ нигезендә, янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда республикада 1–3 куркыныч класслы пиротехник эшләнмәләрне (бенгал утларыннан, хлопушкалардан тыш) куллану тыела. Аларны сәнәгать оешмалары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле) чикләреннән 500 метр ераклыкта аттырырга мөмкин. Шулай ук торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күп булган объектлар, автомобиль юллары, шәхси йорт хуҗалыклары чикләреннән, күп фатирлы йортлардан 30 метр ераклыкта гына кулланырга ярый.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктында «федераль законнар» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 46 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 6^1 бүлек өстәргә:

«6^1 бүлек. **Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлары**

49^1 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү тәртибе**

1. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыра:

1) чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре вәкилләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар өлкәсендә очрашулар, консультацияләр һәм башка чаралар уздыру;

2) чит дәүләтләрнең җирле үзидарә органнары белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турындагы килешүләр (алга таба шулай ук әлеге бүлектә – килешү) төзү;

3) муниципальара хезмәттәшлек өлкәсендә халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашу максатында махсус төзелгән органнар вәкаләтләре кысаларында мондый эшчәнлектә катнашу;

4) муниципальара хезмәттәшлекнең халыкара программалары проектларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

5) законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә.

3. Җирле үзидарә органнары халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруның рәвеше һәм сроклары турында белешмәләр;

2) вәкилләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре хакында белешмәләр;

3) җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләне күрсәтеп, мондый мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру максатлары, халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен тасвирлау;

4) халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру чыгымнарының исәп-хисабы, аңа шул исәптән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру өчен җибәрүгә планлаштырыла торган җирле бюджет акчалары турындагы белешмәләр дә керә.

5. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны килешү төзү рәвешендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, әлеге статьяның 3 өлешендә каралган мөрәҗәгатькә әлеге килешүнең проекты һәм затларның аңа имза салу вәкаләтләрен раслаучы документлар кушып бирелә.

6. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау тәртибен һәм срокларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

7. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.

49^2 статья. **Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында килешүләрне теркәү тәртибе**

1. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү аңа имза салынган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән республика башкарма хакимият органына (алга таба әлеге статьяда – вәкаләтле орган) теркәү өчен тапшырыла.

2. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү белән берьюлы вәкаләтле органга муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан таныкланган түбәндәгеләрнең күчермәләре тапшырыла:

1) имзаланган килешүнең;

2) әлеге Законның 49^1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектының.

3. Вәкаләтле орган җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында тапшырылган килешүне карый һәм килешү тапшырылган көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча аны теркәү хакында йә аны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәү хакында карар кабул итү өчен нигез булып мондый килешүнең әлеге Законның 49^1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектына туры килүе тора.

5. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәүдән баш тарту хакында карар кабул итү өчен нигез булып мондый килешүнең әлеге Законның 49^1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән килешү проектына туры килмәве тора.

6. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәү хакында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган мондый килешүгә теркәү номеры бирә һәм аны килешүне тапшырган җирле үзидарә органына җибәрә. Теркәү номеры бирелгән әлеге килешүнең күчермәсе вәкаләтле органда сакланырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүне теркәүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган, килешүне теркәүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мондый килешүне һәм аңа материалларны килешүне тапшырган җирле үзидарә органына кире кайтара.

8. Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне вәкаләтле орган тарафыннан теркәү мондый килешүләрнең үз көченә керүенең мәҗбүри шарты булып тора.

9. Җирле үзидарә органнарының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турында имзаланган килешүләр муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) өчен каралган тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 122-ТРЗ

Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү (алга таба – патриотик тәрбия) өлкәсендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, патриотик тәрбиянең максатын, принципларын һәм бурычларын билгели.

2. Патриотик тәрбия турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларыннан тора.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында патриотик тәрбия дигәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик, тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның һәм патриотик тәрбиянең башка субъектларының гражданнарда патриотик аң, Туган илгә тугрылык, Ватанны саклау буенча граждан бурычын һәм конституциячел бурычларны үтәргә әзер булу, Ватан тарихына хөрмәт формалаштыру буенча максатчан эшчәнлеге аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Патриотик тәрбиянең максаты, принциплары һәм бурычлары**

1. Патриотик тәрбиянең төп максаты гражданнарда рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәтләр, гражданлыкның асылына туры килүне, конституциячел һәм хәрби бурычка тугрылык, җаваплылык һәм дисциплина формалаштырудан гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбиянең принциплары:

1) гражданнар белән эшләүдә адреслы якын килү;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән үзара эшчәнлегенең системалы булуы һәм аны оештыру;

3) патриотик тәрбия эшчәнлеген оештырганда гражданнарның милли, этномәдәни, конфессиональ үзенчәлекләрен исәпкә алу;

4) гражданнарга патриотик тәрбия бирүдә өзлексезлек һәм дәвамчанлык;

5) патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәләрен бәяләүдә ачыклык һәм мөстәкыйльлек;

6) гаиләне Россия җәмгыятенең нигезе итеп карауны формалаштыру.

3. Патриотик тәрбиянең төп бурычлары:

1) гражданнарга Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен хөрмәт итү, законнарны үтәү рухында тәрбия бирү;

2) гражданнарда Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мәдәни, тарихи үткәненә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт, Ватанга хезмәт итәргә, аны сакларга, граждан бурычын, һөнәри һәм хәрби бурычны намус белән үтәргә әзер булуны формалаштыру;

3) гражданнарда Россия Федерациясе дәүләт символлары, Татарстан Республикасы дәүләт символлары белән горурлану хисе һәм аларга карата хөрмәт уяту;

4) патриотик тәрбия системасын үстерү, дәүләт хезмәтенең абруен арттыру, гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүгә әзерләүне камилләштерү;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү;

6) гражданнарда рухи-әхлакый үсешкә ихтыяҗ һәм өлкән буынга ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру, буыннар арасында бәйләнеш булдыру, өлкәннәргә һәм якын кешеләргә кайгыртучанлык күрсәтү, гаилә институтын ныгыту һәм традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу;

7) халыклар арасында дуслык багланышларын үстерү, милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, экстремизм чагылышларына каршы тору өчен шартлар тудыру.

4 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте**

1. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән үзара эшчәнлектә башкарыла торган патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чаралар җыелмасыннан гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру түбәндәге рәвешләрдә башкарыла:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу;

2) патриотик тәрбия системасын фәнни һәм методик тәэмин итү, патриотик тәрбия эшенең иң уңышлы һәм перспективалы рәвешләрен һәм ысулларын тарату;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә ведомствоара үзара эшчәнлек һәм дәүләти-иҗтимагый партнерлыкны үстерү;

4) балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүне оештыру һәм уздыру, аларның Ватанга хезмәт итүгә мотивациясен, Ватан тарихын өйрәнү белән кызыксынуын арттыру буенча программалар, методикалар эшләү һәм аларны гамәлгә кертү;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү;

6) патриотик тәрбияне мәгълүмати тәэмин итү;

7) тарихи, туган якны өйрәнү буенча һәм мемориаль музейлар булдыру һәм аларны саклау, Россия Федерациясенең хәрби дан көннәрен һәм истәлекле даталарын, Татарстан Республикасының истәлекле даталарын мәңгеләштерүче һәйкәлләр, обелисклар, стелалар, башка мемориаль корылмалар, объектлар урнаштыру һәм аларны төзекләндерү, күргәзмәләр оештыру, хәрби дан урыннарында мемориаль билгеләр урнаштыру;

8) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләү;

9) хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитеп килүче һәм хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җиткән гражданнарның Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүгә әзерлек узуы өчен шартлар тәэмин итү;

10) мәгариф оешмаларының ветераннар оешмалары, сугышчан дан музейлары, шулай ук Бөек Ватан сугышы, хәрби хәрәкәтләр, хәрби хезмәт ветераннары белән үзара эшчәнлеге системасын оештыру һәм үстерү;

11) патриотик юнәлештәге әсәрләр иҗат итүдә сәнгать һәм әдәбият әһелләренә ярдәм күрсәтү;

12) Россия Федерациясенең хәрби дан көннәренә һәм истәлекле даталарына, Татарстан Республикасының истәлекле даталарына багышланган тантаналы һәм истәлекле чаралар оештыру һәм уздыру;

13) патриотик тәрбия өлкәсендәге иҗтимагый проектларга ярдәм итү.

5 статья. **Патриотик тәрбия субъектлары**

Патриотик тәрбия субъектлары:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм аларга ведомство буйсынуындагы оешмалар;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларга ведомство буйсынуындагы оешмалар;

3) мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар;

4) дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары;

5) яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендәге дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар;

6) гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик, тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар);

7) иҗтимагый-дәүләти оешмалар, ветераннар оешмалары, эзләү берләшмәләре һәм патриотик юнәлештәге башка иҗтимагый берләшмәләр;

8) дәүләт һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары;

9) патриотик тәрбия үзәкләре;

10) абруе, патриотизмы, граждан, һөнәри һәм хәрби бурычка тугрылыгы башкалар өчен охшарга тырышу үрнәге һәм өлгесе булган Россия Федерациясе гражданнары.

6 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

2. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) төзү, Координация советы турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

4) патриотик тәрбия өлкәсендә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтүне оештыру;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмаларга булышлык һәм ярдәм күрсәтү;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

4. Мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәгариф оешмаларында укучыларга патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча патриотик юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлек;

3) укучыларда патриотик аң формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм уздыру;

4) патриотик тәрбия буенча укучылар арасында олимпиадалар һәм конкурслар оештыру һәм уздыру;

5) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның хәрби хезмәт нигезләре буенча башлангыч белемнәр алуын тәэмин итү;

6) урта гомуми белем бирү яисә урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында укучыларның хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек үтүен оештыру;

7) мәгариф оешмаларында туган якны өйрәнү хәрәкәте, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү буенча тикшеренү, мәдәни-агарту эшләре үсешенә булышлык күрсәтү;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

5. Яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) яшьләрнең патриотик, сәяси һәм граждан активлыгы, җитлегүе дәрәҗәсен арттыру;

2) граждан-патриотик тәрбиянең яшьләрдә дөрес кыйммәтләр формалаштырудагы ролен көчәйтү;

3) яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын, яшьләр мохитендә милли үзаңны һәм толерантлыкны үстерү;

4) Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) хәрәкәте үсешенә булышлык күрсәтү;

5) патриотик юнәлештәге чаралар оештыру һәм уздыру;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

6. Мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы тарихи вакыйгаларына һәм истәлекле даталарына багышланган чаралар уздыруны оештыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, кинофестивальләр, иҗади семинарлар, тамашачылар белән тематик очрашулар һәм башка чаралар оештыру, шул исәптән аларны уздыру тәртибен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Россиянеке һәм халыкара булган күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, фестивальләрдә һәм конкурсларда катнашу, патриотик темага күргәзмәләр оештыру;

4) Ватанны саклаучы (саклаучылар) һәм аның (аларның) кылган батырлыклары истәлеген мәңгеләштерүгә багышланган иң яхшы музейга (музей экспозициясенә) конкурс уздыру;

5) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

7. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсен һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының барлык яшь төркемнәрендәге халкының физик әзерлек дәрәҗәсен арттыру максатларында физкультура, савыктыру спорт чаралары оештыру;

2) хәрби-гамәли спорт төрләрен пропагандалау;

3) Татарстан Республикасының барлык яшь төркемнәрендәге халкы өчен «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (ГТО) тапшыруны оештыру;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

8. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча вәкаләтләр башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру;

2) патриотизм формалаштыруга булыша торган китаплар һәм басма продукция нәшер итүне һәм таратуны оештыру;

3) патриотик темага журналистлар конкурслары, иҗади конкурслар оештыру һәм уздыру;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

9. Туризм өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләүдә булышлык күрсәтү;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

7 статья. **Патриотик тәрбиядә җирле үзидарә органнарының катнашуы**

1. Җирле үзидарә органнары патриотик тәрбия эшчәнлегендә федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә катнашырга хокуклы.

2. Җирле үзидарә органнары патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны үз эченә алган муниципаль программалар расларга хокуклы.

8 статья. **Координация советы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбиянең башка субъектларының үзара эшчәнлеген камилләштерү максатларында Координация советы төзелә.

2. Координация советы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә һәм консультатив һәм киңәшмә орган булып тора.

3. Координация советы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре кертелә. Координация советы составына, кирәк булганда, патриотик тәрбиянең башка субъектлары вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

4. Координация советы ел саен Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

9 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларда гражданнарның катнашуы**

Патриотик тәрбия, хәрби хезмәтнең абруен арттыру, Ватанны саклауны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнар түбәндәге чараларда катнашырга хокуклы:

1) хәрби каберлекләрне, Ватанны саклаганда һәлак булганнар күмелгән урыннарны саклау һәм төзекләндерү, һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерүче кабер ташлары, һәйкәлләр, стелалар, обелисклар, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнарның батырлыклары белән тарихи бәйләнеше булган аерым территорияләрне саклау һәм төзекләндерү;

3) билгесез хәрби каберлекләрне һәм җирләнмәгән мәетләрне табуга, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен ачыклауга юнәлдерелгән эзләү эшен уздыру;

4) Ватанны саклаганда һәлак булганнар турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, аларның батырлыгына багышланган истәлекле күргәзмәләр оештыру һәм уздыру;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка чаралар.

10 статья. **Патриотик тәрбиядә коммерциягә карамаган оешмаларның катнашуы**

1. Коммерциягә карамаган оешмалар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә оештырырга һәм уздырырга;

2) патриотик тәрбия эшендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка рәвешләрдә катнашырга.

2. Коммерциягә карамаган оешмаларга патриотик тәрбиянең мәдәни, рухи-әхлакый нигезләрен ныгытуда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгечә ярдәм күрсәтә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларындагы патриотик тәрбия чараларында катнашуга җәлеп итү юлы белән;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка рәвешләрдә.

11 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында бу максатларга каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 123-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) (алга таба – Бердәм порталда шәхси кабинет адресы)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «яисә электрон почта адресы» сүзләрен «, электрон почта адресы йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «электрон почта адресын» сүзләреннән соң «йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 8^1 өлеш өстәргә:

«8^1. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә чираттан тыш шәхси кабул ителү хокукына I, II төркем инвалидлары, инвалид балалар һәм мондый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Чираттан тыш шәхси кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби гамәлләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларының, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) кабул итүгә өч яше тулмаган балалар белән килгән гражданнар.

Беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 10 өлештә «9 өлешендәге 1 – 4 пунктларында» сүзләрен «8^1 һәм 9 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга, «шәхси беренче чиратта» сүзләрен «чираттан тыш яисә беренче чиратта шәхси» сүзләренә алмаштырырга;

г) 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 16 статьяның 5 пунктында «электрон почта адресы» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 20 статьяда:

а) 2 өлештә «яисә электрон почта адресын» сүзләрен «, электрон почта адресын йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «электрон почта адреслары» сүзләреннән соң «йә Бердәм порталда шәхси кабинетлар адреслары» сүзләрен өстәргә.

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны гражданнар, гражданнар берләшмәләре, шул исәптән юридик затлар, мөрәҗәгатьләрен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә һәм гавами әһәмиятле функцияләр башкаручы башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына, «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) кулланып, электрон документлар рәвешендә җибәрү һәм күрсәтелгән органнар, оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан мондый мөрәҗәгатьләргә Бердәм порталда мөрәҗәгать җибәргән затның шәхси кабинеты адресы (уникаль идентификаторы) буенча җаваплар җибәрү мөмкинлегенә карата тәэмин итү, әгәр күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр мондый мөмкинлек тәэмин ителмәгән булса, 2025 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча башкарыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 124-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8^1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 пунктта «, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 декабрь
№ 125-ТРЗ

ГАСЫР ЯШЬТӘШЕ

Юбилей

Казанның 80 нче мәктәбе 100 еллык юбилеен уздырды. Өч ел элек аңа күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри исемен биргәннәр.

Эшләтә дә, эшләгәнне күрә дә белгән җитәкче булганда, мәктәпнең уңышлары күп булыр әле.

Мәктәпне Россиянең атказанган укытучысы Роберт Мансуров җитәкли. Элеккеге директор Марс Зиннуров коронавирустан вафат булгач, аны җитәкче итеп куялар. Баксаң, үз гаиләсенә дә бу чир белән көрәшергә туры килгән икән.

– Язмыш шулай хәл итте инде. 2020 елда коронавирус безнең гаиләбезгә дә кагылды. Мин дә, хатыным да чирне бик авыр кичердек. Розалия чирне җиңә алмады. Без ике кыз үстердек. Берсе – Казанда, икенчесе Яшел Үзәндә яши. Балалар янәшәсендә булыйм дип, Казанга күчендем, – ди Роберт Мансуров. – Моңа кадәр Кукмара районының мәгариф идарәсе башлыгы булып эшләдем. Ә Казанның 80 нче мәктәбенә төрле чараларга еш килә идем. Директор вазыйфасына билгеләнгәч, иң әүвәл бу мәктәпнең исемле булуын теләдем. Коллектив белән дә, ата-аналар белән дә киңәшеп, Каюм Насыйри исемен алу буенча документлар әзерли башладык. Бу исем безгә туры килеп тора, ник дигәндә, мәктәп янәшәсендә генә бөек мәгърифәтченең музей-утары урнашкан, ул анда 1887–1902 елларда яшәгән. Безнең укучылар бу музейда еш була һәм төрле мәдәни чараларда катнаша.

Мәктәп белән танышканда, Роберт Мансуров, бездә эшләгән һәр укытучы үз фәнен яратып, булдырам, дип эшли, ди. Моңа без дә инандык. Җитәкчегә булган ихтирамны да, аның башка мөгаллимнәргә булган карашын да тойдык. Директор мәктәпнең һәр кабинеты белән таныштырды. Мактаныргы бар! Кайчандыр агач идәнле бинаны хәзер танып та булмый. Кабинетларга ремонт ясалган, заманча техника белән җиһазланган. Безгә аеруча биология һәм химия кабинетлары ошады. Беренчесенә кергәч, бөтенләй рәхәт мохиткә эләгәсең, әйтерсең, бакчада йөрисең. Ә инде химия кабинетында тәҗрибәләр ясарга барлык мөмкинлекләр тудырылган. Мәктәптә хезмәт дәресләре дә күңелле үтә. Кызлар өчен хәтта тегү машиналары да алып куйганнар.

Директор коллективында эшләүче һәркем белән горурлана.

– Бирегә эшкә килгәндә, югары категорияле 3 укытучы эшли иде. Бүген алар 20дән артык. Фән кандидатларыбыз да өчәү. Берничә ел элек мәктәпкә 13 укытучы җитми иде. Университет җитәкчеләре, студентлар белән сөйләшеп, бар фәннәрдән дә мөгаллимнәр тупладык. Коллективта ике генә ир-ат иде. Берсе – мин, икенчесе – 73 яшьлек физкультура укытучысы. Хәзер мәктәптә уннан артык ир-егет хезмәт куя.

80 нче мәктәпне тәмамлап, инде зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр дә байтак. Алар арасында Камал театры артисты Искәндәр Хәйруллин да бар. Ул кичәне бик матур итеп, мәктәп еллары турында җылы һәм кызыклы хатирәләре белән уртаклашып алып барды. Җырчы Фәрит Таишев та биредә укыган. Кечкенәдән мәктәпнең үзешчән тормышында кайнаган. Ул да истәлекләре белән бүлеште.

Мәктәп коллективын юбилей белән котларга килүчеләрнең барысы да мәктәпнең өч ел эчендә яңартылуына, җиһазлануына сокланды. Милли мирасны, мәдәниятне саклаган өчен рәхмәт тә әйттеләр. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының дәреслекләр бүлеге җитәкчесе Ләйсән Гайфуллина бу мәктәптә даими кунак икән.

– Үткәнне белмәгәннең киләчәге юк, диләр. Ә сезнең мәктәпнең киләчәге бар. Тарихыбызны, традицияләребезне киләчәк буынга тапшыру буенча башкалардан аерылып торасыз, – диде ул. – Узган ел «Татар галимнәре» китабын тәкъдим итү кичәсендә булган идем. Быел Сабантуйга әзерләнүне күзәттем. Соңгы ике елда күпме үзгәреш! Уку йортына Каюм Насыйри исеме бирелде, аңа һәйкәл куелды. Милләтебез өчен башкарган эшләрегезгә рәхмәт!

Рәхмәт, дигәннән, әлеге юбилейда Роберт Мансуровка, коллективта эшләүче бик күп укытучыларга төрле дәрәҗәдәге бүләкләр тапшырдылар. Монысы тагын да сөендерде. Бу укытучыларга канат куйды кебек.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Каюм Насыйри исемендәге 80 нче мәктәптә **800 бала – 21 милләт** вәкиле белем ала. **54 укытучы** эшли. Аларның яртысы **30 яшькә** дә җитмәгән.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы рәисе урынбасары, эчке хезмәт полковнигы **Гайсин** Салават Гаврилович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың салым системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оператив контроль бүлеге башлыгы **Алешин** Андрей Александрович, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш бухгалтеры **Вәлиуллина** Наталья Вадимовна, яшь буынга белем һәм хәрби-патриотик тәрбия бирүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесенең укыту курсы тәрбиячесе **Припутникова** Татьяна Николаевна, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе төркеме (мобилизация чараларын уздыруны тәэмин итү) башлыгы **Успенский** Андрей Николаевич, һөнөри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Гүзәл» нәшрият-полиграфия үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Түбән Кама шәһәре) **Сөләйманов** Адис Кари улы, кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Коры җир гаскәрләре Баш командованиесенең кадрлар бүлеге өлкән офицеры **Прокудина** Наталья Викторовна, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Мәдәниятне үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең кадрлар бүлеге инспекторы **Топорова** Альбина Алексеевна, «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесенең кадрлар һәм строй бүлекчәсе башлыгы **Яббарова** Альбина Миңневәли кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен рәссам-график, «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Әлминова** Инга Байназар кызына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең Келәш авылы китапханәсе әйдәүче китапханәчесе **Галимова** Гөлчәчәк Садертдин кызына, «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Алабуга филиалы мөдире **Данилова** Гөлшат Хаҗи кызына, Татарстан Республикасының «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе мәдәният директоры **Җиһаншин** Рамил Рөстәм улына, «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Мәхмүтов** Марсель Җәмил улына, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары **Натфуллин** Дамир Данил улына, Казан шәһәренең «Рөстәм Яхин исемендәге 3 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы, концертмейстеры **Ногманова** Эльвира Илшат кызына, «Нурлатның «Сәләт» балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хореография классы буенча укытучысы **Хворостьева** Надежда Николаевнага, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Сахаровка авылы мәдәният йорты директоры **Чилибьева** Татьяна Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ДӘШМӘ, ТЕЛЕФОН!

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы законга үзгәрешләр кертелде: дәрестә телефон кулланырга ярамый. Дөрес, кайбер мәктәпләрдә гаджетларны болай да тартмага җыялар. Әмма «без хаклы» дип, күп баланың моңа исе китми иде. Хәзер инде бар да укытучы кушканча булачак!

– Дәресләрдә телефон тыюны әти-әниләр дә, укытучылар да күптән сорый. Законга кертелгән төзәтмәләр уку сыйфатын, тәртипне яхшыртачак. Балалар игътибарын читкә юнәлтмәячәк, бер-берсе белән күбрәк аралашачак, – ди Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин әлеге закон проекты турында.

Сүз уңаеннан, Вячеслав Володин телеграм-каналында мәктәптә телефонны тыюга карата сораштыру да уздырды. Анда катнашучыларның 84 проценты әлеге тәкъдимне хуплады. Димәк, чыннан да, үзәккә үткән мәсьәлә.

Татарстанның кайбер мәктәпләрендә телефоннарны махсус тартмага җыялар. Шул ук вакытта укытучы әйткәнгә исе китмәүчеләр дә юк түгел. Бирмим икән, бирмим! Менә син ул балага аңлатып кара. Балаларның кыйммәтле телефонына, бәласеннән башаяк дип, укытучылар үзләре дә кагылырга курка.

Алабуга шәһәренең 1 нче гимназиясендә телефоннарны җыеп, дәресләр беткәч кенә бирәләр. Шулай килешенгән, берәү дә каршы килми икән.

– Җыймасаң, биремнәрне күчерәләр, карап җитешеп булмый. Ләкин ике телефон белән йөрүче укучылар да бар. Берсен бирәләр, икенчесен үзләрендә калдыралар, – ди укытучы Айгөл Һадиуллина.

Югары Ослан районындагы Иннополис лицееның математика укытучысы, «Ел укытучысы–2023» республика бәйгесе җиңүчесе Арман Костанянның да фикерен белештек.

– Телефон тыюны хуплыйм. Дөрес, аны белем бирүдә дә кулланып була. Ләкин цифрлы җиһазлар кирәк икән, моның өчен ноутбук, планшетлар бар. Мин укучыларыма, икенче дәрескә ноутбук алып килегез, дип алдан әйтеп куям. Әгәр өйләрендә юк икән, мәктәптә бар бит, – ди Арман Костанян.

Аның әйтүенчә, тыю ул – аңлатырга кирәкми дигән сүз түгел. Балаларны телефоннан дөрес итеп файдаланырга өйрәтергә кирәк. Социаль челтәрләрдә уен уйнап, төрле рәсем, видеолар карап, вакытын бушка әрәм итүчеләр бар. Әлегә бар җирдә дә аңлату җитми.

Казандагы «Салават Күпере» микрорайонында яшәүче Камалиевларның кызлары Азалия 3 нче сыйныфта укый.

– Бездә телефонны җыймыйлар иде әле. Белмим, хәзер ничек булыр? Дәрес вакытында аны кулланырга рөхсәт итмиләр. Берәү дә тәртипсезләнми. Кечкенәләр әйткәнне тыңлый бит ул. Уку вакытында аның кирәге дә юк инде. Ә менә дәрес беткәч, өйгә кайтабыз, дип шалтыратырга кирәк, – ди Рәзинә Камалиева.

Әлмәт районының Яңа Кәшер мәктәбе директоры урынбасары Лилия Насыйбуллина фикеренчә, телефон укуга комачаулый. Ләкин цифрлаштыру заманында аннан башка да булмый. Кайбер биремнәрне укучылар еш кына телефонда эшли. Зыяны да бар, әлбәттә. Балалар кирәкмәгән мәгълүмат ала, юк-бар уеннарга вакытын әрәм итә. Фикерләү сәләтен дә арттырмый: барысын да тиз генә интернеттан карап була.

– Әти-әниләр башлангыч сыйныфта ук кыйммәтле телефон сатып ала. Аннан дөрес файдаланырга өйрәтмиләр, нәтиҗәдә балалар үзләре дә белми, безнең сүзгә дә колак салмыйлар. Бу – заман чире. Бу хакта бик нык уйларга кирәк, – ди Лилия Насыйбуллина, борчылуын белдереп.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Булат ЗАКИРОВ, юрист:

– Телефоннарны дәрес вакытында куллану гына тыела. Аны укытучы җыячакмы, әллә букчада торачакмы? Тормышка ашыру механизмы проектта аңлатылмаган. Моны мәктәп үзе хәл итәчәк. Кем төшереп ватты – шул гаепле! Закон проекты өченче укылышта кабул ителеп, Федерация Советына җибәрелде. Президент имзалаганнан соң, үзгәрешләр, рәсми рәвештә басылып чыккач, үз көченә керәчәк.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Бәйрәм

– Шундый хәлләр менә, – дип көрсенде доктор. – Дөрес аңларга тырышыгыз инде...

Хастаханә коридорына чыккач та ул беркадәр исәңгерәп торды, докторның сүзләре кабат колагында яңгыраган кебек булгач кына һушына килде һәм аның белән килешкәндәй, башын кагып куйды:

– Дөрес аңларга кирәк...

Ул тирә-ягына күз йөртеп алды да дәртле һәм сәламәт күренергә теләп, башын югары күтәрде һәм җиңел адымнар белән атлап китте. Җиңел адымнар белән атлау шулкадәр авыр иде. Тик ул бирешмәскә тырышты.

Кинәт ул бәйрәм икәнен аңлады. Әле бая гына башында мең төрле уй, миллион хәстәр иде. Кереп белеп кенә чыгам да тегендә барып киләм, аннан соң монда кагылам... Шунда барып, шуны шулай итеп тә килергә кирәк икән, шуннан соң тагын әллә нәрсәләр... Ә алай итәргә кирәк булмаган. Гомумән, әллә нинди мәшәкатьләр, үзенә дә башкаларга да кирәкмәгән, ләкин кирәкле кебек тоелган эшләр белән маташуның бөтенләй хаҗәте булмаган. Хәтта ул хакта уйлап баш катырып, ми туздырып тору үзе үк исраф гамәл булган. Чөнки бүген – бәйрәм.

Ул монда бөтенләй башка нәрсәне белергә дип кергән иде. Анализларын. Анализларын алып, врач белән сөйләшүгә, бөтен булмышын үзгәртерлек ачыш ясады. Бәйрәм бүген!

Бәйрәм икәнен аңлагач, иңдәге мәшәкатьләр үзеннән-үзе шуып төште, тәне дә, җаны да җиңеләеп, сулышы иркенәеп калды. Мәшәкатьләр, газаплар, кайгылар каядыр эреп югалды, бөтен тирә-якта – матурлык, ә җанында бәйрәм генә калды. Урамга кабат чыгуга ул авыз эченнән дәртле җыр сузып җибәрде. Башын тыныч кына башласа да, тора-бара кызыбрак китте бугай, янына ике тәртип сакчысы килеп басты.

– Гафу итегез, документыгыз?..

Ул шундук, елмаеп, документларын чыгарды:

– Рәхим итегез!

Берсе кәгазьләрне актарырга кереште, ә икенчесе бик сәерсенеп кенә аны күзәтә бирде. Елмаеп, балкып торучы зат һәрвакыт шикле күренә. Бөтен халык кашларын җимереп, ниндидер мәшәкать белән анда-монда чапкан дәвердә, башында – акылы, эчендә җаны булган кеше болай ихлас итеп елмаеп тора алмый. Болай елмаеп тора икән, димәк, ул – я псих, я террорист.

– Кесәләреңне әйләндер әле, – диде икенче тәртип сакчысы. – Сумкаңны да бушат.

Ул елмаеп куйды да зур теләк белән кушылганны үтәде. Тәртип сакчысы бик җентекләп һәр вак-төяк эченнән атом бомбасы йөртүче лайнер килеп чыгар шикелле җитди итеп тикшереп чыкты. Шикле нәрсәсе юк иде. Димәк, псих. Ярый, монысы алар вәкаләте түгел.

– Нәрсә җырлап йөрисең?

– Бәйрәм! – дип сөрәнләде ул, демонстрациягә чыккан кеше сыман.

– Нинди бәйрәм? – дип аптырады тәртип сакчысы, үзенең тагын бер бәйрәмне урамда үткәрүенә үртәлеп. Псих больница ягына ымлагач кына барысын да аңлагандай булды. Димәк, сөенечле хәбәр әйткәннәр. Менә хәзер бар да аңлашыла.

Подъезд алдында ипләп кенә кәгеп торучы ирләрне ул яратмый иде. Йөзләре – йөз, сүзләре сүз түгел. Берәр нәрсә сөйли башласалар, кырык сәгатькә сузалар. Берәр җөмләне тутырып әйтә алсалар, йөзәр тапкыр кабатлыйлар. Гомумән, исерекләрне җене сөйми иде. Үзе айнык чакта. Үзе айнык чакта ул үзенең исерек вакытын да сөйми иде. Ләкин бу юлы әллә кайдан сәлам биреп, барысы белән дә күрешеп чыкты. Шулай ихлас булгач, аның үзен дә салган дип уйладылар һәм йөз грамм коеп бирделәр.

– Юк, егетләр... – дип каршы төште ул. – Бүген миңа эчәргә ярамый. Бүген – бәйрәм.

– Чо, мусульманский что ли? – дип сорады берсе һәм аның җавабын да көтеп тормастан, – ага, тогда понятно, – дип куйды да кыенсынып кына сорады: – А нам можно? Чуть-чуть?

Ул баш кына какты. Һәм ике кулына ике авыр сумка күтәреп кайтып килүче күрше карчыгына каршы атлады:

– Әйдә, күтәрешим.

Карчык рәхмәт укыды. Чөнки ни сәбәпледер лифт эшләми иде. Карчыкны ишек төбенә кадәр озатып куйгач, үз фатирына төште. Тиз генә чәй чөмереп алды да өен җыештырды. Иң матур, иң затлы әйберләрне җәйде. Мондый нәрсәләрне хатыны бәйрәмнәрдә генә куя иде. Аннан соң өстәл әзерләде. Тәмле итеп, мул итеп. Бәйрәмнәрдә генә кия торган матур киемнәрен киде. Өйдәгеләрнең барысы да эштә иде әле. Аларга чылтыратып хәлләрен белеште. Ул шат, бәхетле иде, шуңа ашыкмый-кабаланмый гына сөйләште. Йөзе дә, сүзләре дә балкып тора иде. Моны телефонның теге ягында да сизделәр. «Ни булды?» – дип сорадылар. Һәм шундук үзләрен төзәтергә ашыктылар:

– Ә-ә-ә... Димәк, сөенечле хәбәр әйттеләр! Урра!

– Бәйрәм бүген! – дип елмайды ул. – Бәйрәм. Кайтасызмы әле?..

Шул рәвешле хатыны белән дә, балалары белән дә сөйләшеп чыккач, күңеле тагын нурланып киткәндәй тоелды. Әллә кайчан шулай итәргә кирәк булган югыйсә, гел ашык-пошык кына, гел эш арасында гына сөйләшәләр дә бер-берсенә булган күңел җылысын сиздерә алмыйлар иде. Хәзер ул гел шушылай итәчәк. Чөнки бәйрәм... Бүген дә... Иртәгә дә... Аннан соң да... Һәрбер көне бәйрәм... Чөнки аның көннәре санаулы калган иде.

Спорт

Мондый футбол кемгә кирәк?

Кышка кергәндә спорт җәмәгатьчелегендә янә шул сорауга җавап эзли башладылар. Россиядә футбол сезонын элеккеге кебек яз башлап, көз тәмамлауны хуплаган белгечләр аз түгел. Бәхәс кышкы тәнәфескә чыккач та дәвам итәчәк. «Рубин» футболчылары исә ялга яхшы кәеф белән китте. Казан командасы турнир таблицасында җиденче урынга күтәрелде.

Россия премьер-лигасында кышкы тәнәфес алдыннан соңгы очрашу Калининградта узды. Илнең иң көнбатышындагы шәһәрдә җирле «Балтика» белән «Рубин» очрашты. Узган сезонда ике команда беренче лигада уйнады һәм премьер-лигага чыгу өчен көрәшкән төп командалар булып саналды. Сезон беткәнче диярлек «Балтика» алда барды. Әмма ахырда «Рубин», Калининград командасын җиңеп, беренче урынны яулады. Премьер-лигага икесе дә чыктылар. Ә хәлләре төрлечә. «Балтика» иң көчлеләр ярышында турнир таблицасында астан караганда икенче урында урнашса, Казан командасы ничек тә өскәрәк күтәрелү ягын карый.

Матчта ниләр булганын бәйнә-бәйнә сөйләп торуның мәгънәсе юк. Әле алтынчы минутта ук туп кертеп, «Рубин» ахырга кадәр әнә шул өстенлекне саклап калырга тырышты һәм булдырды да. 1:0 исәбе белән җиңеп, Казан командасы җиденче урынга күтәрелде. Мондый уен – Рәшит Рәхимов командасының төп үзенчәлегенә әверелде. «Рубин» премьер-лигада 18 очрашуда 8 җиңү яулады. Шулардан алтысын 1:0 исәбе белән отты. 8 октябрь белән 9 декабрь арасында Казан командасы 8 очрашуда 6 җиңү яулады, 1 тапкыр ничьяга уйнады, 1 мәртәбә оттырды. 19 очкога ия булу өчен безнекеләр нибары 7 гол кертте! Шуңа күрә Рәшит Рәхимовны хәзер Корбан Бәрдыев белән чагыштырулары гаҗәп тә түгел.

Дөрес, мондый уен һәркемнең дә күңеленә хуш килми. Ләкин иң мөһиме – сезон ахырындагы нәтиҗә. Ә башында – беренче 8 очрашуда нибары бер тапкыр откан вакытта Рәхимовны отставкага җибәрү турында сүзләр чыккан иде. Әмма тәҗрибәле остаз элеккеге тренерлардан калган составны аралап, аларга яңа килгәннәрне кушып, нәтиҗәгә ирешерлек команда туплый алды. Яхшымы-яманмы, әмма команда үз уенын тапты. Кышкы тәнәфес нинди йогынты ясар? Футболчылар ике атналык ялга китте. Ә гыйнвар уртасында чемпионатның язгы өлешенә әзерлек башлана.

Хәер, язгы дип шартлы рәвештә генә әйтелә инде. 19 тур очрашулары 2 мартка билгеләнгән. Ул вакытта нинди һава торышы буласын кем белгән? Бу хакта сүз кузгату да юкка түгел. Соңгы көннәрдә футбол җәмәгатьчелегендә шау-шуга әверелгән бәхәс купты. Россия җыелма командасы һәм «Ростов»ның баш тренеры Валерий Карпин өстән кар явып торганда туп тибәргә рөхсәт биргән кешене «ахмак» дип атады. Аңа дорфалыгы өчен дисквалификация җәзасы бирделәр, ләкин проблема барлыгын да кире кагып булмый. Ник без кыш көне футбол уйныйбыз? Кар яуганда туп күренмәгән, ә салкында футболчы да, тамашачы да чыдый алмаган матчлар кем өчен уза? Футбол очрашуы интегү түгел, тамаша булырга тиеш бит инде. Белгечләр арасында Россиядә футбол сезонын элеккечә – язын уйный башлап, көзен тәмамларга тәкъдим итүчеләр дә аз түгел. Мондый система 2010 елга кадәр гамәлдә иде. Ә аннары зур клублардагы хуҗаларның яңача яшисе, Европадагы кебек уйныйсы килде. Шулай итеп, футбол сезонын җәен башлап, икенче елның язында тәмамлый башладык. Имеш, болай итсәк, Европа турнирларында да җиңә башлаячакбыз. Җиңүләр дә килмәде, Европа да ерагайды. Кар гына элеккечә ява, кышлар гына туп типмәслек суыклар алып килә. Мондый футбол кемгә кирәк?

Илнар ХӨСНУЛЛИН

	Команда	У	О
1	Краснодар	18	38
2	Зенит	18	36
3	Динамо	18	32
4	Локомотив	18	31
5	Спартак	18	30
6	Крылья Советов	18	29
7	Рубин	18	28
8	ЦСКА	18	28
9	Пари НН	18	24
10	Ростов	18	21
11	Факел	18	21
12	Урал	18	19
13	Ахмат	18	17
14	Оренбург	18	15
15	Балтика	18	13
16	Сочи	18	11

ЯЛЛАР КӨТКӘНДӘ...

Күпләр зарыгып көткән Яңа ел яллары һәм балаларның кышкы каникулы якынлаша. Ул озын ялларны берәүнең дә заяга уздырасы килми, билгеле. Әйтик, Казанда яшәүчеләр яки башкалага кунакка килүчеләр өчен нинди чаралар әзерлиләр икән? Балаларны кайларга алып барырга? «ВТ» шуларны белеште.

Балаларның кышкы каникулы 30 декабрьдән алып 8 гыйнвар аралыгында. Яңа ел яллары исә 1–8 гыйнвар көннәренә туры килә.

Сүз уңаеннан, Казан кышкы ялларны уздыру өчен иң популяр шәһәрләр бишлегенә кергән. SuperJob хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге каникулын Мәскәү, Сочи, Байкал күле, Санкт-Петербург һәм Казан шәһәрләрендә уздырырга тели.

Мәдәни программа

Елдагыча, Казан театрлары һәм башка мәдәният учаклары Яңа елга махсус программа әзерли. Әйтик, Камал театры быел балалар өчен театральләштерелгән Яңа ел квесты уздырачак. «Шәрык клубы»нда да ялларда төрле чаралар узачак. Тинчурин театры исә узган елгы «тылсымлы» тамашаны күрсәтергә җыена. Кариев театрында нәниләр өчен махсус тамаша 21–29 декабрьдә көненә икешәр мәртәбә куелачак. Алар бу юлы Көлсылу турындагы әкияткә чакыра.

Казанның Парклар һәм скверлар дирекциясе дә җәмгысы 1,8 млн сумлык тамашалар күрсәтергә әзерләнә. Алар барысы да шәһәр паркларында, скверларда, төрле торак комплексларында – кыскасы, саф һавада узачак. Әйтик, «Могҗизалар автобусы» дип исемләнгән тамаша 1, 2, 3 гыйнвар көннәрендә Бауман урамында, Горки-Әмәт урманында, «Ак чәчәкләр» бульварында, «Салават Күпере» торак комплексында һәм «Крылья Советов» паркында узачак.

Казанның төп чыршысы янындагы мәйданның – үз программасы. Әйтик, 4 гыйнвар кичендә анда җырлы-биюле «Татарча Яңа ел» узачак.

Актив ял

Ашыйсы тәм-томнар ашалгач, өйдә ятып туйгач, саф һавага чыгып, ялның актив өлешенә күчәргә була. Авыл җирендә аңлашыла инде: кар көрәп керсәң дә, чаңгыга басып, урам әйләнсәң дә – артык баш ватасы юк. Ә Казанда бу кышта 102 шугалак (шул исәптән, 83 хоккей тартмасы), 15 чаңгы трассасы эшләячәк. Спорт сөючеләр өчен 200ләп чара узачак. Бәяләргә килгәндә, тимераякта шууның бер сәгате уртача – 150–250 сумга (үз тимераягың белән – 50–150 сум), чаңгыда шууның бер сәгате уртача 200–300 сумга төшәчәк.

Ә авылда?

Әтнәдә яшәүче өч бала әнисе, шагыйрә Гөлүсә Батталова авыл җирендә дә ялларны күңелле итеп уздырырга була дигән фикердә. Фантазияңне эшкә җигеп, иренмичә, барысын да алдан планлаштырсаң, бигрәк тә.

– Хәзер бит авыл җирендә яшәүче балаларның да саф һавада йөрергә вакытлары юк. Укудан кайталар да дәрес хәзерләргә утыралар, түгәрәкләрдән дә кайтып кермиләр диярлек. Шуңа да кышкы каникулны быел да саф һавада уздырырга ниятлибез. Кар көрәп, тау шуып, чаңгы шуып… Безнең янәшәдә генә тау бар, кары да явып тора. Аннан соң, ел саен Әтнә театрында уза торган Яңа ел тамашасын да калдырмыйбыз. Өйдә дә гаилә белән бергә төрле фильм-мультфильмнар карарга тырышабыз, – дип сөйләде ул. – Быел менә тагын балаларны Казанга алып барырга ниятлибез. Алар өчен ул – үзе бер сәяхәт. Бу юлы балалар өчен кызыклы булырдай музейга кереп чыгарбыз дигән фикер бар. Кыскасы, ялларны хәлебездән килгәнчә матур һәм күңелле итеп уздырырга тырышабыз.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Озын ялларда Казанда кая барып, ниләр карарга? Экскурсовод Җәмилә ЛОКМАНОВА киңәшләре.

Балалар белән

1 Гаилә үзәге янындагы төп чыршы һәм «боз шәһәрчеге».

2 Горки-Әмәт урманы. Монда чаңгы шуарга, саф һавада йөрергә яки бәйрәм тамашаларын карарга килергә була.

3 «Ривьера» янындагы күзәтү тәгәрмәче. Ул тулысынча ябык, анда җылы. Кичен Яңа ел утларыннан җемелдәүче шәһәрне күзәтү аеруча рәхәт булыр.

4 «Хәзинә» музей комплексында урнашкан Татарстанның табигый тарих музее. Балаларның ялын файдалы да, кызыклы да итәргә яхшы урын.

5 Кремль яр буендагы шугалак. Андагы әкияти матурлык бер генә баланы да битараф калдырмас.

Зурлар өчен

1 Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрындагы тамашалар.

2 Казан Кремле ишегалдындагы Яңа ел ярминкәсе (ул 20 декабрьдән 15 гыйнварга кадәр узачак).

3 Татарстан Милли китапханәсе. Озын кышкы кичләрне бушка уздырмас өчен, моннан китаплар алырга мөмкин.

4 Казанның Мәрҗани һәм Каюм Насыйри урамнары. Монда да ел саен чыршы бизәлгән була.

5 Черек күлдәге шугалак.

«СЕЗДӘ НИЧӘ ГРАДУС?»

Кыш хикмәтләре

Бу көннәрдә иртән социаль челтәрләрдән көн саен ишелеп килә торган «Хәерле иртә!»ләргә, чәчәкле-чуклы открытка-теләкләргә яңа эчтәлектәге сүзләр өстәлде. Әлеге хәбәрләр гадәттә «Сездә ничә градус?» дип башлана.

Авылныкылар шәһәрдәгеләрдән: «Фатирыгыз җылымы, машинагыз кабындымы?» – дип сораса, шәһәрнекеләр (авыл белән элемтәсе өзелеп бетмәгәннәр): «Малларыгыз нишли? Туңмыйлармы?» – дип, абзардагыларның хәл-әхвәлен белешә. Аннары гына: «Газ-электрлар бетмәдеме?» – дип сорый. Машиналарга чират ахырдан. Чөнки беләләр: мондый салкыннарда авылның җанын авырттырган үзгә проблемасы – туңганын да, өшегәнен дә әйтә белми, хуҗаларының күзләренә генә карап тора торган мал-туары бар. Авыл кешесе үзеннән дә битәр әнә шул җан ияләре өчен борчыла. «Үзебез җылы, якты өйләрдә, хайваннарга бигрәк салкын», – дип уфтана ул.

Ике авыл кешесе очрашса да, хәл сорашу дигәнең: «Малларыгызны нишләттегез?» – дип, үзара тәҗрибә уртаклашуга кайтып кала. Хәзер бит авылларда да агачтан бурап ясалган абзарлар юк. Күп кешедә блоктан, кирпечтән өелгән яки беркадәр җылытылган заманча материаллардан эшләнгән тораклар. Маллар ел әйләнәсе бер үк урында асрала (элек салкыннарда бура абзарларга күчерәләр иде). Шунлыктан эре мал күп булган тораклар җылырак була, җәен, киресенчә, андагы малларны эсселек, һавасызлык, чебен җәфалый. Тик бүген инде җәйге эсселәрдә әлсерәгәннәре, болыт күк ябылган чебеннәре онытылды, салкыннарда аларга барыбер җылырак, дип шөкер итәсең (чебен димәктән, кайбер шаянрак кешеләр әле дә, урамга чыгып, туңып кергән саен: «Аның каравы чебен юк», – дип сөенә икән. Оптимистлар һәрнәрсәдән бер плюс таба).

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Малларыгызны нишләттегез?» дигән сорауга җаваплар төрле. Кемдер: «Кырдагылар ачлы-туклы да йөри әле, түзәрләр», – ди ваемсыз гына. Битараф булмаганнар исә ишекләрен дә өстәмә җылыта, бүлемнәрне дә тышкы яктан иске юргандыр, паластыр, калын җәймә ише әйберләр белән төрә. Малларга суны да кайнаррак, ризыкны да туклыклырак, мулрак бирергә тырыша.

Башка елны, сыер булганлыктан, бозаулар туңар дип уйлап та карамый идек. «Аномаль суыклар килә», – дип, алдан куркытуларның бер файдасы булды: абзарның буш өлешенә салам-печән түшәреп өйдек, урам ягына стена буйлап ике рәт түкле салам тездек, асларына калынрак итеп түшәдек. Аларга иптәшкә җиде песи дә кереп кунаклады. Гомер булмаганны, берсе шул көннәрдә бәбиләгән булып чыкты. Инде аларын өйгә алып керәсе булырмы дигән идем, тирән итеп саламны казып түшеп, урын ясап бәбиләгән икән. Шөкер, дүрт бәбие дә исән-сау, песиләр (ни дисәң дә, җидесе дә ана!) аларга туңарга ирек бирми. Башка елны этебез салкыннарда да беркайда тормый, кая гына кертсәк тә, өреп, чыгам дип, еламсырап, үз оясына чыгарта иде. Быел картайды шул, өстәвенә корсак астыннан зур гына шеш тә асылынып төште. Көннәр суыта башлауга, ул үзе, ярдәм сораган кебек, оясына да кермичә, тәрәзә каршында әрле-бирле йөри башлады. «Әйдә», – диюемә, абзарга йөгерә-йөгерә керде мескенкәй, сыер торган урынга бәйләдек. Ничә көннәр тынын да чыгармый. Шулай итеп, бер абзарга сан ягыннан җан ияләре шактыйга җыйналды. Тик абзар гына сыер торгандагы кебек түгел, җылылык чыганагы да ул булган икән шул…

Гомер булмаганны, бу юлы синоптикларның: «Аномаль салкыннар килә», – дигән хәбәре сәгате-минуты белән, хәтта әйткән градусларына кадәр туры килде. «Инде салкыннар бу атнада чигенә, көннәр җылыта», – дигән хәбәрләре дә рас килсә иде. Үзебездән бигрәк, мал-туарлар өчен дип көтәбез.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 365

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+